КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2019 ел, 24 сентябрь

г.Казань

№ 876

Индустриаль парклар инфраструктурасы объектларын төзү, модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләү чыгымнарын каплау өчен индустриаль паркларның идарә итүче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2017 – 2021 елларга Татарстан Республикасы территориясендә муниципаль дәрәҗәдәге индустриаль (сәнәгать) парkларны һәм сәнәгать мәйданчыкларын төзү һәм үстерү» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Индустриаль парклар инфраструктурасы объектларын төзү, модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләү чыгымнарын каплау өчен индустриаль паркларның идарә итүче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 24 сентябрь, 876 нчы
карары белән расланды

Индустриаль парклар инфраструктурасы объектларын төзү, модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләү чыгымнарын каплау өчен индустриаль паркларның идарә итүче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе

1. Бу Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары нигезендә эшләнде һәм индустриаль парклар инфраструктурасы объектларын төзү, модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләү чыгымнарын каплау өчен индустриаль паркларның идарә итүче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен, максатларын һәм шартларын билгели.

2. Бу Тәртиптә кулланыла торган төп төшенчәләр:

индустриаль парк – паркның бердәм операторы (идарә итүче компания) тарафыннан идарә ителә торган, индустриаль парк резидентларының сәнәгать җитештерүен төзү, модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләү өчен билгеләнгән коммуналь һәм транспорт инфраструктурасы, биналар, төзелмәләр һәм корылмалар объектлары комплексы;

индустриаль парк проекты – индустриаль парк инфраструктурасы объектларын төзү, модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләү буенча проект;

идарә итүче компания – Россия Федерациясе законнары нигезендә оештырылган, индустриаль парк белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы һәм Татарстан Республикасының вәкаләтле органы белән индустриаль парк проектын тормышка ашыру турында килешү төзегән яки Татарстан Республикасының башкарма хакимият органы карары белән индустриаль парк белән идарә итү эшчәнлегенә вәкаләтле булган коммерция оешмасы;

резидент – индустриаль парк территориясендә проектны тормышка ашыручы юридик зат яки индивидуаль эшмәкәр;

коммуналь инфраструктура – электр, газ, җылылык, су белән тәэмин итү, су чыгару, электр энергетикасы, элемтә өлкәләрендә индустриаль парк резидентлары эшчәнлеген тәэмин итә торган капиталь төзелеш объектларының элемтә, электр, газ, җылылык, су белән тәэмин итүнең, су чыгаруның инженерлык системаларына тоташтыру (технологик тоташтыру) нокталарына кадәр хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән объектлар һәм инженерлык корылмалары, шулай ук каты көнкүреш калдыкларын юкка чыгару, зарарсызландыру һәм күмү өчен файдаланыла торган объектлар комплексы;

транспорт инфраструктурасы – индустриаль паркның үз территориясендә яки аның янындагы территориядә урнашкан һәм индустриаль парк резидентларының транспорт чаралары хәрәкәтен тәэмин итү, шул исәптән автомобиль юллары, тимер юллар, портлар, тоннельләр, эстакадалар, күперләр, тимер юл кичүләре һәм юлүткәргечләр өчен билгеләнгән күчемсез мөлкәт объектлары җыелмасы;

индустриаль парклар резидентлары өчен билгеләнгән биналар, төзелмәләр һәм корылмалар – сәнәгать эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен күчемсез мөлкәт объектлары комплексы.

3. Субсидия тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм тиешле финанс елына субсидия бирү өчен бюджет акчасын алучы буларак Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына (алга таба – Министрлык) билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

4. Индустриаль паркның идарә итүче компаниясе субсидия бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзергә планлаштырыла торган айга кадәр килә торган айның 1енә кадәр түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча башкарылмаган йөкләмәләре булмаган;

Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты алдында үз вакытында түләнмәгән башка бурычлары булмаган;

үзгәртеп оештыру, бетерелү, банкротлык процессында булмаган;

чит ил юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталларында теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән салым салуның ташламалы салым режимы һәм (яки) финанс операцияләре үткәргәндә мондый юридик затларга мөнәсәбәттә мәгълүматны ачу яки бирү күздә тотылмаган дәүләт яки территория (офшор зоналар) булган чит ил юридик затлары өлеше гомумән алганда 50 проценттан артып киткән Россия юридик заты булмаган;

бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен башка норматив хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмаган;

Министрлык белән индустриаль парк проектын тормышка ашыру графигын һәм индустриаль паркның Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Индустриаль парклар, сәнәгать технопарклары һәм югары технологияләр өлкәсендәге технопарклар инфраструктурасы объектларын төзү, модернизацияләү һәм реконструкцияләү чыгымнарын каплау өчен субсидияләр рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтүдән файдалану хокукына ия булган Россия Федерациясе субъектларын сайлап алу турында» 2014 елның 30 октябрендәге 1119 номерлы карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1119 номерлы карары) нигезендә субсидияләр рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтүдән файдалану хокукына ия булган Россия Федерациясе субъектларын сайлап алу кагыйдәләренең III бүлегендәге 15 нче пункты белән билгеләнгән күрсәткечләрнең мәгънәләренә тигез һәм (яки) алардан артып киткән

финанс-икътисадый күрсәткечләрен күздә тота торган хезмәттәшлек итү турында килешүе булган;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Индустриаль (сәнәгать) парклар һәм индустриаль (сәнәгать) паркларның идарә итүче компанияләре турында» 2015 елның 4 августындагы 794 номерлы карары белән билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәүгә раславы булган.

5. Идарә итүче компания тарафыннан объектларның төзү, модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләү чыгымнары капланырга тиешле индустриаль парклар инфраструктурасына коммуналь, транспорт инфраструктурасы объектлары, шулай ук индустриаль парклар резидентлары өчен билгеләнгән биналар, төзелмәләр һәм корылмалар керә.

Инфраструктура объектлары индустриаль парк проектының бизнес-планы (алга таба – бизнес-план) белән билгеләнә.

Каплау өчен субсидия бирелә торган чыгымнарның юнәлеше – индустриаль парк инфраструктурасы объектларында авторлык күзәтчелеген, проект-тикшеренү һәм төзелеш-монтаж эшләрен гамәлгә ашыру.

6. Субсидия, агымдагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджетында субсидия бирү өчен күздә тотылган бюджет ассигнованиеләре күләменнән артмаган күләмдә расланган бизнес-план нигезендә индустриаль парк проектын тормышка ашыра башлаганнан алып, бу Тәртипнең 5 нче пунктында күрсәтелгән юнәлешләр буенча өстәлгән кыйммәткә салымны исәпкә алмыйча, идарә итүче компания тарафыннан фактта тотылган чыгымнар күләмендә бирелә.

Чыгымнарны каплауга субсидия күләмен исәпләү түбәндәге формула буенча гамәлгә ашырыла:

$$С_{вз} = З_1 + З_2 + З_3 + ... + З_n,$$

монда:

$С_{вз}$ – субсидия күләме;

$З_1$, $З_2$, $З_3$... $З_n$ – бу пунктның беренче абзацы нигезендә чыгымнарның түбәндәге юнәлешләре буенча, өстәлгән кыйммәткә салымны исәпкә алмыйча, фактта тотылган чыгымнар: индустриаль парк инфраструктурасы объектларында авторлык күзәтчелеген, проект-тикшеренү һәм төзү-монтаж эшләрен гамәлгә ашыру.

7. Нәтиҗәлелек күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:

резидентларның җыелма табышы;

булдырылган эш урыннары саны;

резидентлар саны;

җыелма өстәлгән кыйммәт.

Нәтиҗәлелек күрсәткечләренең мәгънәләре килешүдә Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1119 номерлы карары таләпләрен исәпкә алып билгеләнә.

8. Субсидия алу өчен идарә итүче компания, агымдагы финанс елының 18 декабреннән дә соңга калмыйча, Министрлыкка түбәндәге документлар белән гариза тапшыра:

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча гариза;

салым органының килешү төзергә планлаштырыла торган айга кадәр килгән айның 1енә карата бирелгән, Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар

турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча идарә итүче компаниянең бурычлары булмавын раслый торган белешмә кәгазен;

идарә итүче компания җитәкчесе тарафыннан имзаланган килешү төзергә планлаштырыла торган айга кадәр килгән айның 1енә идарә итүче компаниянең үзгәртеп оештыру, бетерү, банкротлык процессында булмавы турындагы белешмә кәгазен;

идарә итүче компаниянең гамәлдәге гамәлгә кую документлары күчермәләрен;

идарә итүче компания җитәкчесе вәкаләтләрен раслый торган документлар күчермәләрен;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

эшләрне тапшыру-кабул итү актлары күчермәләрен (проект-тикшерenү эшләре, авторлык күзәтчелеге, төзелеш контроле һ.б. булган очракта);

КС-3 формасы буенча индустриаль парк инфраструктурасы объектларын төзүгә, модернизацияләүгә һәм (яки) реконструкцияләүгә башкарылган эшләрнең һәм чыгымнарның кыйммәте турындагы белешмә кәгазьләре күчермәләрен;

КС-2 формасы буенча индустриаль парк инфраструктурасы объектларын төзүгә, модернизацияләүгә һәм (яки) реконструкцияләүгә башкарылган эшләрне кабул итү турындагы актлар күчермәләрен;

индустриаль парк инфраструктурасы объектлары буенча подрядчы оешма белән төзелгән шартнамәләр, контрактлар, килешүләр күчермәләрен;

башкарылган эшләр өчен түләүне раслый торган түләү документлары күчермәләрен;

проект документларына һәм мондый проект документларын әзерләү өчен башкарылган инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе күчермәләрен;

дәүләт экспертизасының төзелеш объектлары сметасы кыйммәте дөрес булу турындагы уңай бәяләмәсе күчермәләрен;

дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе белән расланган объектларны төзү, модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләү кыйммәтенең җыелма смета исәп-хисаплары күчермәләрен;

индустриаль паркның финанс-икътисад моделен үз эченә алган бизнес-планын, мастер-планын, капиталь төзелешнең һәр объекты буенча эшләр башкару вакытларын үз эченә алган һәм Министрлык тарафыннан расланган форма буенча җентекле план-графикны;

субсидияләнә торган һәр төзү, модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләү объекты буенча исемен, кыйммәтен, сорала торган субсидия күләмен, тапшырылган җыелма смета исәп-хисаплары кысаларында элегрәк бирелгән субсидия күләмен күрсәтеп, Министрлык тарафыннан расланган форма буенча исәп-хисап белешмә кәгазен;

Министрлык белән индустриаль парк проектын тормышка ашыру графигын һәм индустриаль паркның Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1119 номерлы карарының III бүлегендәге 15 нче пункты белән билгеләнгән күрсәткечләрнең мәгънәләренә тигез һәм (яки) алардан артып киткән финанс-икътисадый күрсәткечләрен күздә тота торган хезмәттәшлек итү турындагы килешүне;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Индустриаль (сәнәгать) парклар һәм индустриаль (сәнәгать) паркларның идарә итүче компанияләре турында» 2015 ел-ның 4 августындагы 794 номерлы карары белән билгеләнгән таләпләргә туры килүне раслый торган документ.

Идарә итүче компания бу пунктның өченче һәм җиденче абзацларында күрсәтелгән документларны Министрлыкка тапшырмаска хокуклы.

Идарә итүче компания тарафыннан бу пунктның өченче һәм җиденче абзацларында күрсәтелгән документлар тапшырылмаган очракта, Министрлык аларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

9. Идарә итүче компания Министрлыкка тапшырылган мәгълүматларның дөреслеге өчен законнар нигезендә җавап бирә.

Барлык тапшырыла торган документлар төгәл басылган һәм һәр пункты тутырылган булырга тиеш (мәгълүматлар булмаган очракта, сызык куела). Чистартып төзәтүләр һәм төзәтмәләр ясау (мөһер сугылган (мөһер булганда) һәм вәкаләтле зат имзасы белән расланган төзәтмәләрдән тыш) рөхсәт ителми. Заявканың барлык битләре нумерланган булырга тиеш. Документлар тегелгән һәм заявканың ахыргы битендә, битләрнең гомуми санын күрсәтеп, идарә итүче компаниянең мөһере (мөһер булганда) һәм аңа вәкаләте булган затының имзасы белән расланырга тиеш.

10. Министрлык гаризаны нумерланган, җеп белән тегелгән һәм мөһер сугылган журналга кергән көнендә теркәүгә алынган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә терки, тапшырылган документларны карап тикшерә һәм субсидия бирү турында яки субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

11. Субсидия бирү турында карар кабул ителгән очракта, Министрлык әлеге карарны кабул иткән көннән өч эш көне эчендә идарә итүче компания белән килешү төзи.

12. Субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, Министрлык әлеге карарны кабул иткән көннән бер көн эчендә документларны, кабул ителгән карарның нигезләре күрсәтелә торган хәбәрнамәне теркәп, идарә итүче компаниягә кире кайтара.

13. Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

идарә итүче компаниянең бу Тәртипнең 4 нче пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве;

идарә итүче компания тарафыннан тапшырылган документларның бу Тәртипнең 9 нчы пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве яки бу Тәртипнең 8 нче пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау) (бу Тәртипнең 8 нче пунктындагы өченче һәм җиденче абзацларында күрсәтелгән документлардан тыш);

идарә итүче компания тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмавы.

14. Субсидия Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма буенча төзелгән килешү нигезендә бирелә.

Килешүдә субсидия күләме; аның максатчан билгеләнеше; каплау өчен субсидия бирелә торган чыгымнар юнәлешләре; субсидияне күчерү вакытлары һәм тәртибе; субсидия күчерелә торган счетлар; нәтиҗәлелек күрсәткечләренең мәгънәсе; түбәндәге хисап документларын теркәп, субсидия бирүнең нәтиҗәлелеге

күрсәткечләренә ирешү турында хисап документларын тапшыру вакытлары һәм формалары: дәүләт төзелешен күзәтчелеге органының төзелгән, реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объектының техник регламентлар һәм проект документлары таләпләренә, шул исәптән энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектын кулланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән тәэмин итү таләпләренә туры килүе-килмәве турындагы бәяләмәсе һәм субсидияләнә торган объектны файдалануга тапшыру акты; субсидияне кире кайтару очрагы; идарә итүче компаниянең һәм субсидияләр бирү турындагы шартнамәләр (килешүләр) буенча йөкләмәләрне үтәү максатларында төзелгән шартнамәләр (килешүләр) буенча тәэмин итүчеләр (подрядчылар, үтәүчеләр) булган затларның Министрлык һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары тарафыннан субсидия бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешенә тикшерүләрне гамәлгә ашыруга ризалыгы; бу Тәртип һәм төзелә торган килешү шартларын үтәү турында нигезләмәләр; идарә итүче компаниянең кабул ителгән йөкләмәләрне үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән, шул исәптән нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешмәгән, шулай ук субсидия бирү тәртибен, максатларын һәм шартларын бозган өчен җаваплылыгы; нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешмәгәндә кулланыла торган штраф санкцияләре карала.

15. Министрлык субсидияне идарә итүче компаниянең Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яки Россия Федерациясе территориясендә теркәлгән кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап счетына йә килешү төзелгән көннән биш эш көне эчендә Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган шәхси счетка бер тапкыр күчерә.

16. Министрлык һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары идарә итүче компаниянең бу Тәртип һәм килешү белән билгеләнгән субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра.

17. Министрлык һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары тарафыннан субсидия бирү шартлары һәм тәртибе бозылу, шул исәптән нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешмәү фактлары билгеләнгән очракта, субсидия идарә итүче компания тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә кире кайтарылырга тиеш.

18. Идарә итүче компания тарафыннан бу Тәртипнең 17 нче пунктында күрсәтелгән субсидияне кире кайтару вакыты бозылганда, Министрлык субсидияне Татарстан Республикасы бюджетына Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә кире кайтару буенча чара күрә.

19. Субсидияләр алучылар Министрлыкка килешү белән билгеләнә торган вакытлар һәм формалар нигезендә субсидиядән файдалану һәм субсидия бирүнең нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү турында хисаплылык тапшыра.

Идарә итүче компания тарафыннан килешүдә күрсәтелгән нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешелмәгән булса, Министрлык штраф санкцияләрен куллана. Бу очракта штраф санкцияләренең күләме түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$A = \left( \sum_{i=1}^{4} \left( 1 - \frac{d_i}{D_i} \right) \times X \right) \times V,$$

монда:

A – штраф санкцияләренең күләме;

i – субсидия бирү турындагы килешүдә күрсәтелгән нәтиҗәлелек күрсәткечләре саны;

$d_i$ – субсидия бирү турындагы килешүдә күрсәтелгән нәтиҗәлелекнең i-күрсәткеченең ирешелгән мәгънәсе;

$D_i$ – субсидия бирү турындагы килешүдә күрсәтелгән нәтиҗәлелекнең i-күрсәткеченең план мәгънәсе;

X –хисап чорының соңгы көне хәленә карата Россия Федерациясе Үзәк банкындагы төп ставканың $\frac{1}{300}$ га тигез булган төзәтү коэффициенты;

V – идарә итүче компания тарафыннан алынган субсидия акчасының күләме.

Нәтиҗәлелек күрсәткечләренең берсен исәпләгәндә факттагы мәгънәсе план мәгънәсеннән артып киткән булса, бу күрсәткеч буенча формуланың мәгънәсе $\left(1-\frac{d_i}{D_i}\right)$ нульгә тигез итеп алына.

20. Субсидия бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүдә тоту Министрлык, дәүләт финанс тикшерүе органнары тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.